КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 март г.Казань № 113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча төбәк программасын (чаралар планын) раслау турында» 2023 ел, 27 июнь, 756 нчы карары белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча төбәк программасына (чаралар планына) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча төбәк программасын (чаралар планын) раслау турында» 2023 ел, 27 июнь, 756 нчы карары белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча төбәк программасына (чаралар планына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең утызынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлекнең 3.2 пунктындагы 3 графасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин